## Аңлатма язуы.

Чистай “1нче урта гомуми белем бирү мәктәбендә” “Йолдызчык” әдәби-театр түгәрәге эшли. Бу түгәрәк укучыларның артистлык сәләтен, сәнгатьле сөйләм күнекмәләрен, логик фикерләүләрен үстерү максатыннан чыгып оештырылды. “Йолдызчык” түгәрәге, исеменнән үк күренгәнчә, театр, сәнгать, җыр-бию яратучы укучыларны туплады. Бу түгәрәк шулай ук сәхнә серләренә төшенү, кулдан матур киемнәр әзерләү һәм зәвыклы киенү, тамашачылар алдында үз-үзеңне тотарга өйрәнү бурычларын үз эченә ала.

Түгәрәктә сәләтле балалар белән күмәкләп, шулай ук индивидуаль эшләү дә урын алган. Чөнки мәктәбебездә сәнгать сөюче балалар бик күп, араларында матур җырлаучылар, биюгә оста кызлар-малайлар бар. Шундыйларны сайлап алып һәм теләк-хыялларын истә тотып эшләү уңышлы булыр диген фикергә килдем.

“Йолдызчык” драма түгәрәге берләшмәсенә 8-13 яшьлек укучылар тупланды. Түгәрәк атнага 1 сәг. Исәбеннән үткәрелә .

## Максат:

“Шәхес формалаштыруга юнәлтелгән технология аша укучыларда әдәбиятка-сәнгатькә мәхәббәт тәрбияләп, иҗади үсешләрен булдыру”.

## Бурычлар:

- Укучыларны түгәрәк эшенә җәлеп итү, театр белән кызыксыну уяту.
- Сәнгать әсәрләренә мәхәббәт уяту.
- Укучыларның артистлык сәләтен, иҗади талантларын күрә, уңышларга дәрт уята алуга ирешү.
- Сәнгатьле сөйләм күнекмәләрен үстерү.

**(68 сәгать. Атнасына 2 сәгать.)**

| Темалар | Бүлекнең максаты һәм бурычлары | Төп эчтәлеге |
|---|---|---|
| **Исәнме, театр (1ч)** | | |
| Тема 1. Кереш дәрес | Балаларны «Театр” төшенчәсе белән таныштыру. Хыяллану, артистларча уйнау теләге тудыру. | Балаларны театр белән таныштыру.Театр төрләре(драма, курчак, комедия) белән таныштыру.Рәсемнәр, иллюстрацияләр карау. |
| **Театр –нур ул! (2 ч)** | | |
| Тема 1. Татар театры тарихы | Театрның тарихы белән таныштыру. Актёр, режиссёр, рәссам, композитор кебек һөнәр ияләренә кызыксыну уяту. Сәхнә, кул чабу, тамашачы кебек сүзләр ярдәмендә сүзлек байлыгын арттыру.Театрның әһәмиятен аңлату. | Укытучы сөйләме,презентация карау, әңгәмә. |
| Тема 2. Театр нигә кирәк? | | Театр турында әңгәмә, яңа сүзләр белән танышу. Уеннар уйнау. |
| **Сәхнә осталыгының нигезе.Дикция өстендә эш. (6)** | | |
| Тема 1. Актёрлык осталыгының нигезләре | Уен аша балаларның тышкы кыяфәтләрен үзгәртергә этәрү (мимика, жест). | Күнегүләр үтәү. «Эмоцияләр”уенын үткәрү. Күнегүләргә бәя бирү, мактау, бер-берсенә ярдәм итү. |
| Тема 2. Кешенең тавыш тембры, сөйләме. Татар авазлары белән эшләү. | Тиешле образны тудыру өчен хәрәкәт, поза, тавыш интонациясен кулланып үзлектән кирәкле тел чараларын кулланырга омтылыш уяту. Татар авазларын әйтергә , уенда кулланырга өйрәтү. | Сөйләм тембрын, интонациясен үзгәртеп күнегүләр үткәрү. |
| Тема 3. Жест, мимика, хәрәкәт. | Хайваннарның холкын,тормыш рәвешен күрсәтү өчен сыгылмалы хәрәкәтләр ясарга өйрәтү.Иҗади якын килү, хыялыйлыкны үстерү. | Видеофильмнар карау,балаларның хәрәкәтчәнлеген үстерү. |
| Тема 4.Сәхнәдәш белән иҗади хезмәттәшлек | Сәхнәдә үз-үзен тотарга өйрәтү.Бер-беренә карата мөнәсәбәтләрен | Сәхнәдә үзләрен тотышларын бәяләү, киңәшләшү, ярдәм итү. |

| | | |
|---|---|---|
| | күрсәтү.Авазлар белән эшләүне дәвам итү. | |
| Тема 5.Сәхнәдә кешеләр белән аралашу.(практика) | Үз мөмкинлекләреңне бәяли белергә, үзанализ ясарга өйрәнү. | Төрле ситуацияләр аша килешүгә китерүче күнегүләр үткәрү. |
| Тема 6.Үзешчәннәр театрына сәяхәт. | Иҗатка карата кызыксыну уяту,театр сәнгатен танып-белүне активлаштыру. | Театрда тәртип саклау кагыйдәләрен өйрәнү. |
| **Театр –нур ул! (4 сәг.)** | | |
| Тема 1.Татарстан театрлары белән таныштыру. | Татарстанның төрле шәһәрләрендә урнашкан театрлар белән танышу. Г. Камал исемендәге драма һәм комедия театры, К. Тинчурин театры һ.б. | Видеоязмалар,иллюстрацияләр күрсәтү. |
| Тема 2. Татарстан театрлары белән таныштыру. | Яшь тамашачылар театры, Курчак театры белән танышу | Видеоязмалар, презентацияләр күрсәтү. Әңгәмә. |
| Тема3. Театр артистлары. | Шәүкәт Биктимеров, Рәшит Шамкай, Нәҗибә Ихсанова, Исламия Мәхмүтова, Рөстәм Гайзуллин кебек легендар һәм яшь артистлар белән танышу | Артистлар катнашында спектакльләрдән өзекләр карау. |
| Тема 4. Актер һөнәренең үзенчәлекләре. | Актерлык һөнәренең үзенчәлекләрен барлау, оста булуның серләренә төшенү. | Әңгәмә, аралашу, фикер алышу. |
| **Театр эшчәнлеге. (12 ч)** | | |
| Тема 1. Сүзсез хәрәкәтләр белән эмоцияләрне аңлата белү | Игътибарлылык, күзаллау, хыялыйлык хисе тәрбияләү. Импровизация,артистлылык аша матурлыкка омтылыш тәрбияләү.Гәүдә сыгылмалылыгы белән хисләрне белдерергә өйрәтү. | “Сын”, “Реклама” уеннары уйнау. |
| Тема 2. Әсәрне сайлау , аның белән җентекләп танышу. | Әсәрне сәнгатьле уку, укылган өлешләрне күзаллау, балаларның бер-берсенә ярдәмләшүен тәэмин итү. | Әсәрнең аерым өлешләрен уйнап карау. |
| Тема 3. Рольләрне бүлү, рольләргә бүлеп уку. | Диалог вакытында мимика һәм хәрәкәт өстендә эшләү. Дикциягә әһәмият бирү. | Төгәл дикцияне, интонацияне үстерүгә юнәлтелгән уеннар уйнау. |
| Тема 4. Сөйләм техникасын, сәхнәдәге хәрәкәтләрне үстерү, | Балаларны әсәрдәге персонажлар белән таныштыру, аларның характерлары, гадәтләре | Әсәрнең өлешләрен уйнау, кушып спектакль дәрәҗәсенә китерү. |

| | | |
|---|---|---|
| ныгыту буенча репетиция. | турында сөйләшү, аерым өлешләрен сәхнәдә уйнау. | |
| Тема 5. Сөйләм техникасы буенча эш. | Укучыларның коммуникатив, ритмик, музыкаль сәләтләрен үстерү өстендә эш. | Образ тудыру һәм сәхнә тирәлеген дөрес файдаланырга өйрәтү. |
| Тема 6. Хәрәкәт техникасы өстендә эш. | Образ тудыру һәм сәхнә тирәлеген дөрес файдаланырга өйрәтү. | Төрле рольләргә караган хәрәкәтләрне күрсәтү, кабатлау, өйрәнү. |
| Тема 7. Спектакльгә әзерлек. (практика) | Балаларны декорацияләр куярга, сәхнәне бизәргә өйрәтү.Спектакль уңышлы үтәчәгенә ышаныч тәрбияләү. | Сәхнә әзерләү. Авыр очракларда киңәшләр бирү. |
| Тема 8. Спектакль буенча репетиция. (практика) | Балаларны спектакльне тоярга,чыгыш алдыннын тәртип сакларга өйрәтү. Бердәмлек, ярдәмчеллек тәрбияләү. | Репетиция барышында сөйләм, хәрәкәт техникасына,персонажларның бер-берсе белән дөрес аралашуына игътибар итү. |
| Тема 9. Афишалар әзерләү. | Афишаларны дөрес, зәвыклы итеп ясарга өйрәтү. Ата-аналарны да бу эшкә җәлеп итү. | Афиша үрнәкләрен күрсәтү. |
| Тема 10. Спектакль буенча генераль репетиция ясау. | Сәхнәдә рольгә кереп китү, әйләнә-тирәдә дөрес хәрәкәт итү, ситуациягә карап импровизациягә әзер булу күнекмәләрен ныгыту. | Сәхнәдә репетиция ясау. |
| Тема 11. Практик эш: куелачак спектакльне репетиция видеоязмаларыннан карау. | Тамаша вакытында тәртип кагыйдәләрен кабатлау, зәвыклылык формалаштыру. | Спектакльне карау. |
| Тема 12.Спектакль буенча фикер алышу. | Спектакльне әзерләү этапларын аңларга өйрәтү,такт хисе һәм рухи үзенчәлек тәрбияләү. | Спектакль буенча фикер алышу. |
| **Башлангыч сыйныфлар өчен спектакль күрсәтү. (1 ч)** | | |
| **Халык авыз иҗаты (9 сәг.)** | | |
| Тема 1. Мәкальләр белән танышу. | Халык мәкальләрен укып, мәгънәсен аңларга өйрәтү. Халыкның бай мирасына сакчыл караш тәрбияләү. | Әдәп, акыл, тел турында мәкальләр өйрәнү. |
| Тема 2.Әйтемнәр белән танышу. | Әйтемнәрдә халыкның акылы, күзәтүчәнлеге, игътибарлылыгы чагылышын күрсәтү. | Әйтемнәр уку,истә калдыру буенча уеннар уйнау. |

| | | |
|---|---|---|
| Тема 3.Тизәйткечләр белән танышу.(3-4дәр.) | Тел байлыгын үстерү, сөйләм телен баету, тел чарлау. | Тизәйткечләр уку буенча ярышлар , уеннар үткәрү. |
| Тема 4.Бишек җырлары, такмаклар белән танышу. | Халык моңын тыңларга, такмакларын өйрәнергә омтылыш уяту. | Бишек җырлары, такмаклар уку, тыңлау, җырлау. |
| Тема 5.Әкиятләр белән танышу | Әкиятләрнең тәрбияви максатын аңлау, хыял, күзаллау кебек хисләрне үстерү. | Әкиятләр уку, видеоязмалар карау. |
| Тема 6. Халык уеннары белән танышу. | Уеннар аша игътибарлылык, зирәклек, дөрес хәрәкәтләнү, оешканлык, дустанә мөнәсәбәт тәрбияләү. | Халык уеннары уйнау. |
| Тема 7. Милли бәйрәмнәр | Сабантуй, Карга боткасы, Нәүрүз кебек милли бәйрәмнәр, йолалар белән танышу. | Видеоязмалар карау, күргән йолалар турында әңгәмә, уеннар. |
| Тема 8. Мини-сабантуй үткәрү. (практика) | Укучыларның тизлеген, зирәклеген, илтифатлылыгын үстерә торган уеннар, ярышлар үткәрү. Татар милли уеннарына кызыксыну уяту. | Уеннарда, ярыш-бәйгеләрдә катнашу.Канәгатьлелек хисе тәрбияләү. |
| **Татар халкының милли костюмнары, ашлары(9 сәг.)** | | |
| Тема 1.Татар милли киемнәре. Ирләр киеме. | Татар милли ирләр киемнәренә кызыксыну уяту, аларның җайлылыгына, хәрәкәткә комачауламавына игътибар итү. Камзул, читек, билбау сүзләре белән танышу. | Ирләр өчен милли киемнәрне тотып, киеп карау. |
| Тема 2-3. Хатын-кызлар киеме. | Хатын-кыз милли киеменә кызыксыну уяту.Калфак , читек, бала итәкле күлмәк кебек яңа сүзләрне бала сөйләменә кертү.Киемнәрнең ачык төстә булуына игътибар итү. | Хатын –кызлар өчен милли киемнәрне тотып, киеп карау. |
| Тема 4.Бизәнү әйберләре. | Татар халкының бизәнү әйберләре белән таныштыру.Зәвыклылык. матурлыкка омтылыш тәрбияләү.Алка, чулпы, күкрәкчә кебек яңа сүзләрне сөйләмгә кертү. | Иллюстрацияләр, рәсемнәр, презентация карау. |

| | | |
|---|---|---|
| Тема 5.Милли ашлар. | Чәк-чәк, кабартма, кош теле , гөбәдия, коймак кебек татлы ризыклар белән танышу. Дирбиясе белән танышу. | Иллюстрацияләр, видео карау |
| Тема 6. Милли ашлар | Өчпочмак, вак бәлеш, итле бәлеш кебек итле милли ашлар белән танышу, дирбиясен өйрәнү. | Иллюстрацияләр, видео карау |
| Тема 7.Практик эш. Милли ашлар пешерү. | Технология бүлмәсендә гади милли ашларын (коймак, өчпочмак)пешереп карау. Әниләре белән өйдә әзерләнгән ризык алып килү... | Ашларны пешереп карау, әңгәмә, ярдәмчеллек тәрбияләү.<br>Чәй эчү. |
| Тема8.Җырлы –биюле кичә үткәрү. | Милли кимнәр киеп милли уеннар уйнау, такмаклар башкару,татар биюенең серләренә төшенү. | Җырлы, биюле уеннар уйнау, ярдәмчеллек, бердәмлек тәрбияләү. |
| *Тема 9. Үзлектән эш: Татар халкының милли костюмнары, ашлары* | Милли костюмнар, ашларны белү, истә калдыру максатыннан әзерләнгән сорауларга җавап бирү.Татар милли орнаменты белән костюмнарны бизәү. Милли ашлар, киемнәр белән, татар халкының рухи байлыгы белән горурлану хисе тәрбияләү. Һәр эшкә иҗади якын килү теләген уяту. | Рәсем ясау, сорауларга җавап бирү. |
| **Татар язучылары, шагыйрьләре белән танышу(5сәг.)** | | |
| Тема 1.Г. Тукай-бөек шагыйрь. | Г. Тукайның шигырьләре, әкиятләре белән танышу. Олылар өчен дә шигырьләр язуын искәртү.Кечкенә әсәрләрен сәхнәдә уйнап карау. Бөек шагыйрьнең шигырьләрен укырга, теләк тудыру. | Бөек шагыйрьнең шигырьләрен уку., ятлау |
| Тема 2. Ш. Галиев шигырьләре белән танышу. | Ш. Галиев шигырьләре белән танышу.Шигъри әсәрләрне укырга омтылыш уяту. | Ш. Галиев әсәрләрен уку. |
| Тема 3. Ф. Яруллин әсәрләре күңелгә якын. | Ф. Яруллин иҗаты белән танышу.Әкиятләренең тәрбияви максатны күздә | Ф. Яруллин әсәрләрен сәнгатьле уку. |

| | | |
|---|---|---|
| | тотуын, шигырьләренең тирән мәгънәле булуын укучыларга җиткерү. | |
| Тема 4. Роберт Миңнуллин- балалар шагыйре дә. | Р. Миңнуллин иҗаты белән танышу. Кечкенәләр өчен язылган шигырьләренең максатчанлыгын, кызыклы, мавыктыргыч булуына игътибар итү. | Р. Миңнуллин шигырьләрен уку. |
| Тема 5. Шигырь бәйрәме. | Алда өйрәнгән авторларның шигырьләрен, әкиятләрен сәнгатьле итеп уку. | Шигырьләр уку, бүләкләү. |
| **Сәхнә илһам китерә. (9 сәг.)** | | |
| Тема 1. Ф. Яруллинның “Зәңгәр күлдә ай коена” әкиятен уку, җентекләп танышу | Әсәрне сәнгатьле уку, укылган өлешләрне күзаллау, Балаларның бер-берсенә ярдәмләшүен тәэмин итү. | Әсәрнең аерым өлешләрен уйнап карау. |
| Тема 2. Рольләрне бүлү, рольләргә бүлеп уку. | Диалог вакытында мимика һәм хәрәкәт өстендә эшләү. Дикциягә әһәмият бирү. | Төгәл дикцияне, интонацияне үстерүгә юнәлтелгән уеннар уйнау. |
| Тема 3. . Сөйләм техникасын, сәхнәдәге хәрәкәтләрне үстерү, ныгыту буенча репетиция. | Балаларны әсәрдәге персонажлар белән таныштыру, аларның характерлары, гадәтләре турында сөйләшү, аерым өлешләрен сәхнәдә уйнау. | Әсәрнең өлешләрен уйнау, кушып спектакль дәрәҗәсенә китерү. |
| Тема 4. . Сөйләм техникасы буенча эш. | Укучыларның коммуникатив, ритмик, музыкаль сәләтләрен үстерү өстендә эш. | Образ тудыру йәм сәхнә тирәлеген дөрес файдаланырга өйрәтү. |
| Тема 5. . Хәрәкәт техникасы өстендә эш. | Образ тудыру һәм сәхнә тирәлеген дөрес файдаланырга өйрәтү. | Төрле рольләргә караган хәрәкәтләрне күрсәтү, кабатлау, өйрәнү. |
| Тема 6. . Спектакльгә әзерлек. | Балаларны декорацияләр куярга, сәхнәне бизәргә өйрәтү.Спектакльуңышлы үтәчәгенә ышаныч тәрбияләү. | Сәхнә әзерләү. Авыр очракларда киңәшләр бирү. |
| Тема 7 Спектакль буенча репетиция. | Балаларны спектакльне тоярга,чыгыш алдыннын тәртип сакларга өйрәтү. Бердәмлек, ярдәмчеллек тәрбияләү. | Репетиция барышында сөйләм, хәрәкәт техникасына,персонажларның бер-берсе белән дөрес аралашуына игътибар итү. |

| | | |
|---|---|---|
| Тема 8. Афишалар әзерләү. | Афишаларны дөрес, зәвыклы итеп ясарга өйрәтү. Ата-аналарны да бу эшкә җәлеп итү. | Афиша үрнәкләрен күрсәтү.Авырсынган очракларда киңәш бирү. |
| Тема 9. Спектакль буенча генераль репетиция ясау.(практика) | Сәхнәдә рольгә кереп китү, әйләнә-тирәдә дөрес хәрәкәт итү, ситуациягә карап импровизациягә әзер булу күнекмәләрен ныгыту. | Сәхнәдә (костюмнар киеп, декорацияләр белән) репетиция ясау. |
| **Спектакльне ата-аналарга, укытучыларга, мәктәп балаларына күрсәтү.(1 сәг.)** | | |
| **Хәтер китабы (3 сәг.)** | | |
| Тема 1.Тирә-якны өйрәнү музеена сәяхәт. | Туган якның тарихы белән танышу. Музейда үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен истә тоту.Игътибарлылык, кызыксыну хисе тәрбияләү. | Музейда үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен истә тоту.Экспонатлар белән танышу. |
| Тема 2. “Хәзинә” паркындагы милли байлык. | Чистай шәһәре һәм районында туып- үскән, иҗат иткән язучы-шагыйрьләребезнең сыннары янында шигырьләр, әсәрләреннән өзекләр уку,тормыш юлы белән танышу. | “ Хәзинә” паркы буенча сәяхәт. |
| Тема 3.Казан музейларына виртуаль сәяхәт. | Казан музейларына карата кызыксыну уяту, анда булу, экспонатларны чынлыкта күрү теләге уяту. | Видеоязмалар, иллюстрацияләр карау. |
| **Алга, һәрвакыт алга! (4 сәг.)** | | |
| Тема 1-4. Мәктәп , район, республика бәйгеләрендә катнашу | Мәктәп , район, республика бәйгеләрендә катнашу өчен нигезләмәләр белән танышу.Катнашучыны билгеләү. Репетицияләр ясау. | Репетицияләр ясау, костюмнар, декорацияләр әзерләү, бер-берсенә булышу, киңәш бирү теләге тәрбияләү. |
| **Йомгаклау. (2 сәг.)** | | |
| Тема 1-2. Түгәрәкнең эшен тәмамлавы. Җырлы-уенлы кичә уздыру.Укучыларның һәрберсен актив булуы, ярдәмчеллеге,артистлык хисен тоярга өйрәнүе өчен кечкенә бүләкләр, мактау кәгазьләре тапшыру. | Укучыларны сәхнәдә иркен тотарга , уеннарда актив катнашырга, дөрес сөйләм күнекмәләрен истә тотарга , үз-үзләрен тоту кагыйдәләрен үтәргә тәкъдим итү. | Җырлы-уенлы кичә уздыру.Укучыларның һәрберсен актив булуы, ярдәмчеллеге,артистлык хисен тоярга өйрәнүе өчен кечкенә бүләкләр, мактау кәгазьләре тапшыру. |

## Түгәрәкнең сентябрь аена эш планы.

| № | Эш төре | Җаваплы кеше. |
|---|---|---|
| | | Түгәрәк җитәкчесе |
| 1. | Укучыларны туплау. Түгәрәкнең эш планы белән таныштыру. Инструктаж үткәрү. | |
| 2. | Оештыру эшләре. Түгәрәк әгъзаларының бурычлары. | |
| 3. | **Исәнме, театр**<br>Сәнгатьле сөйләм күнекмәләрен үстерү. | |

## Түгәрәкнең октябрь аена эш планы.

| № | Эш төре | Җаваплы кеше. |
|---|---|---|
| | | Түгәрәк җитәкчесе |
| 1. | **Театр –нур ул!** | |
| 2. | Сәхнә өчен куелган уеннарны өйрәнү. | |
| 3. | Сәхнә серләренә өйрәнү. Видеоязмалар карау. | |
| 4. | Киенү-бизәнү осталыгы. Декорациянең роле. | |
| 5. | Татар халык иҗаты. Татар халык җыры өйрәнү. Җырлар тыңлау. Бишек җырлары. | |

## Түгәрәкнең ноябрь аена эш планы.

| № | Эш төре | Җаваплы кеше. |
|---|---|---|
| | **Сәхнә осталыгының нигезе.Дикция өстендә эш.** | |
| 1. | Актёрлык осталыгының нигезләре | |
| 2. | Кешенең тавыш тембры, сөйләме. Татар авазлары белән эшл | |
| 3. | Жест, мимика, хәрәкәт. | |
| 4. | Сәхнәдәш белән иҗади хезмәттәшлек | |
| | | |

## Түгәрәкнең декабрь аена эш планы.

| № | Эш төре | Җаваплы кеше. |
|---|---|---|
| | | Түгәрәк җитәкчесе |
| 1. | Татарстан театрлары белән таныштыру. | |
| 2. | Театр артистлары. | |
| 3. | Актер һөнәренең үзенчәлекләре. | |
| 4. | Сүзсез хәрәкәтләр белән эмоцияләрне аңлата белү | |

## Түгәрәкнең январь аена эш планы.

| № | Эш төре | Җаваплы кеше. |
|---|---|---|
| | | Түгәрәк җитәкчесе |
| 1. | Әсәрне сайлау , аның белән җентекләп танышу. Рольләрне бүлү, рольләргә бүлеп уку. | |
| 2. | Сөйләм техникасын, сәхнәдәге хәрәкәтләрне үстерү, ныгыту буенча репетиция. | |
| 3. | Г.Тукай әсәрләре буенча спектакльгә әзерлек. (практика)<br>Спектакль буенча репетиция. (практика)<br>Афишалар әзерләү. | |

## Түгәрәкнең февраль аена эш планы.

| № | Эш төре | Җаваплы кеше. |
|---|---|---|
| | | Түгәрәк җитәкчесе |
| 1. | Спектакль буенча генераль репетиция. | |
| 2. | Практик эш: куелачак спектакльне репетиция видеоязмаларыннан карау.<br>Спектакль буенча фикер алышу. | |
| 3. | Мәкальләр белән танышу.<br>Әйтемнәр белән танышу. | |

| | | |
|---|---|---|
| | | |
| 4. | Тизәйткечләр белән танышу.(3-4дәр.)<br>Бишек җырлары, такмаклар белән танышу | |

## Түгәрәкнең март аена эш планы.

| № | **Эш төре** | **Җаваплы кеше.**<br>**Түгәрәк җитәкчесе** |
|---|---|---|
| 1. | Әкиятләр белән танышу | |
| 2. | Халык уеннары белән танышу. | |
| 3. | Милли бәйрәмнәр | |
| 4. | Мини-сабантуй үткәрү. (практика) | |
| 5. | Татар милли киемнәре. Ирләр киеме.<br>Хатын-кызлар киеме. Бизәнү әйберләре. | |

## Түгәрәкнең апрель аена эш планы.

| № | **Эш төре** | **Җаваплы кеше.**<br>**Түгәрәк җитәкчесе** |
|---|---|---|
| 1. | Милли ашлар белән танышу<br><br>Практик эш. Милли ашлар пешерү.<br>Җырлы –биюле кичә үткәрү. | |
| 2. | Ф. Яруллинның “Зәңгәр күлдә ай коена” әкиятен уку, җентекләп танышу<br>Рольләрне бүлү, рольләргә бүлеп уку. Сөйләм техникасын, сәхнәдәге хәрәкәтләрне үстерү, ныгыту буенча репет | |
| 3. | Афишалар әзерләү.<br>Спектакль буенча генераль репетиция ясау.(практика) | |
| 4. | Г. Тукай-бөек шагыйрь. . Роберт Миңнуллин- балалар шагыйре дә.<br>Ш. Галиев шигырьләре белән танышу. | |

## Түгәрәкнең май аена эш планы.

| № | Эш төре | Җаваплы кеше.<br>Түгәрәк җитәкчесе |
|---|---|---|
| 1. | Тирә-якны өйрәнү музеена сәяхәт.“Хәзинә” паркындагы милли байлык.<br>Казан музейларына виртуаль сәяхәт.<br><br>Мәктәп , район, республика бәйгеләрендә катнашу<br><br>Түгәрәкнең эшен тәмамлавы. Җырлы-уенлы кичә уздыру.Укучыларның һәрберсен актив булуы, ярдәмчеллеге,артистлык хисен тоярга өйрәнүе өчен кечкенә бүләкләр, мактау кәгазьләре тапшыру. | **Ел буена** |
| 2. | Мәктәп , район, республика бәйгеләрендә катнашу | **Ел буена** |
| 3. | Эшләгән эшләргә анализ, нәтиҗә. | |
| 4. | Түгәрәкнең эшен тәмамлавы. Җырлы-уенлы кичә уздыру.Укучыларның һәрберсен актив булуы, ярдәмчеллеге,артистлык хисен тоярга өйрәнүе өчен кечкенә бүләкләр, мактау кәгазьләре тапшыру. | |